**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең Чүти торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» октябрь, 2019 № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең Чүти торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә алып барырга.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- материаллар сатып алып, буаны ремонтлау;
- материаллар сатып алып җәяүлеләр өчен күперләрне ремонтлау;
- материаллар сатып алып, кое һәм чишмәләр территориясен төзекләндерү;
-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- материаллар һәм җайланмалар сатып алып, зиратларның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау;
- материал алып зират коймасы тоту;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов